| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.10.2020 ел Баулы шәһәре №194

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган Муниципаль мөлкәт булган җир участогын торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Ана (гаилә) капиталы белән эш итүгә бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 мартындагы35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган Муниципаль мөлкәт булган җир участогын торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарына 7 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

Административ регламентка 1нче кушымтада:

3.1) пунктчасында:

- «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «күрсәтелгән Федераль закон нигезендә алар турында белешмәләр проблемалы объектларның бердәм реестрына кертелгән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектларын төзүне тәмамлау» сүзләрен өстәргә;

- «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе А.А. Михайловага йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров